Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыены

КАРАРЫ

2022 елның 19 ноябре №2

## 2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль Иске Шөгер авыл җирлегенең Иске Шөгер торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Иске Шөгер авыл җирлеге Иске Шөгер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар; хәрби хәрәкәт ветераннары; көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, саны 18 яшькә җиткән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санының 30%ыннан арта алмый торган халыктан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- С. Садри урамында юлга вак таш җәю (сатып алу, төяү, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- территорияне механикалаштырылган һәм кулдан чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү (килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- килешү буенча тракторчы хезмәтләре өчен түләү (территорияне коры-чүп үләннәреннән чабу, кардан чистарту, полосаларны минераллаштыру һәм башка эш төрләре);

-МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

- чәчәк үсентеләре сатып алу;

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм Җирләү урыннарын карап тоту:

- коры һәм чүп үләннәрен чабу, карт, авария хәлендәге агачларны кисү, килешү буенча түләү;

- зират өчен чүп контейнерлары сатып алу.

5) ялны оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмасы хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру:

- «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй», «Яңа ел»бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Иске Шөгер авылы, Совет урамы, 1 нче йорт (җирле үзидарә бинасы), Совет урамы, 3 нче йорт

буенча (балалар бакчасы бинасы), М. Җәлил урамы, 33 нче йорт, Иске Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
"Иске Шөгер авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова